Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-5**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 31 октябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль юл фондын оештыру турында” XXIX-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга тәңгәлләштерү максатларында, 2019 елның 2 августындагы “Бюджетара мөнәсәбәтләрне камилләштерү максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында” 307-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 31 октябрендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль юл фондын оештыру турында” XXIX-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктча белән тулыландырырга:

“4) транспорт салымыннан җирле бюджетлар керемнәренең (әгәр Татарстан Республикасы законы белән транспорт салымыннан җирле бюджетларга чигерүләрнең бердәм нормативлары билгеләнгән булса).”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов